ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Лельвиж авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 гыйнвар 3нче номерлы

Лельвиж авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Лельвиж авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 20 ноябрендәге Лельвиж авыл җирлеге Советының 29 номерлы карарына ( Лельвиж авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы, 2015 елның 27 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 12 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның7 ноябрендәге 25 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 20 декаберендәге 35 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 25 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Лельви авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы ____________ Э.Ю. Игнатьева

СОВЕТ ЛЕЛЬВИЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕЛЬВИЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753254
ИНН 1623003890